**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«20» 11 2025 ел Яр Чаллы ш. № 3842

ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Миләшкәй» балалар бакчасы тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставының 29 статьясы 20 пункты, «Муниципаль мәгариф оешмалары хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 10 январендәге 4 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Миләшкәй» балалар бакчасы тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 1 кушымта нигезендә расларга.
2. ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Миләшкәй» балалар бакчасы тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 2 кушымта нигезендә расларга.
3. Карарның гамәлдә булуы 2025 елның 01 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны ТР Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
5. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 11 декабрендәге 5537 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы вазыйфаларын башкаручы Э.Р. Низамиевага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Н. Маняпов

Муниципаль район Башкарма комитетының 2025 елның «20» 11 3842 номерлы карарына 1 кушымта

2025 елның 1 октябреннән ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе - «Миләшкәй» балалар бакчасы буенча түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бер тәрбияләнүчегә бәяләр прейскуранты

| № | Хезмәтнең исеме | Хезмәт бәясе (сум) | Хезмәт күрсәтү дәвамлылыгы |
|---|---|---|---|
| 1 | «Звукознайка» | 600,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 2 | «АБВГДейка» | 600,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 3 | «Буквоед уеннары» | 600,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 4 | «Развивайка» | 600,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 5 | «Здоровячок» | 500,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 6 | «Тхэквондо» | 500,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 7 | «Яшь шахматчы» | 500,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 8 | «Грация» | 500,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 9 | «Яшь рәссам» | 500,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 10 | «Могҗизалы камыр» | 500,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 11 | «Тылсымлы куллар» | 500,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |

2026 елның 1 январеннан

| № | Хезмәтнең исеме | Хезмәт бәясе (сум) | Хезмәт күрсәтү дәвамлылыгы |
|---|---|---|---|
| 1 | «Звукознайка» | 650,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 2 | «АБВГДейка» | 650,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 3 | «Буквоед уеннары» | 650,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 4 | «Развивайка» | 650,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5 | «Здоровячок» | 550,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 6 | «Тхэквондо» | 550,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 7 | «Яшь шахматчы» | 550,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 8 | «Грация» | 550,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 9 | «Яшь рәссам» | 550,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 10 | «Могҗизалы камыр» | 550,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 11 | «Тылсымлы куллар» | 550,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |

ТР Тукай муниципаль районы
муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү
учреждениесе - «Миләшкәй»
балалар бакчасы мөдире _______________ Е.А. Воробьева

«Бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт
күрсәтү үзәге» МБУ җитәкчесе урынбасары _______________ Р.Р. Йосыпова

ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе - «Миләшкәй» балалар бакчасы тарафыннан түләүле хезмәт күрсәтүгә бәяләр прейскурантына кушымта

1. **«Звукознайка»** - программа балаларда грамотага тиешле әзерлек булдыруга, балаларны уку, тиз уку күнекмәләренә өйрәтүгә юнәлтелгән. Әлеге хезмәт 6 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә, кабинетның мәйданы 69,2 кв.м, балалар саны - 21.

2. **«АБВГДейка»** - программа баланың шәхси һәм танып белү тәҗрибәсен киңәйтү шартлары буларак сөйләм эшчәнлеген үстерүгә һәм камилләштерүгә юнәлтелгән. Әлеге хезмәт 5 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә, кабинетның мәйданы 69,9 кв.м, балалар саны - 19.

3. **«Буквоед уеннары»** - программа мәктәпкәчә яшьтәге балаларның мәктәпкә өйрәтүгә мотивациясен үстерә, танып белү процессларын канәгатьләндерүгә, иҗат шатлыгын канәгатьләндерүгә юнәлдергән; фикерләү операцияләрен (анализ, синтез, чагыштыру, классификаөия, аналогия) формалаштыруга, образлы һәм вариатив фикерләүне үстерә, баланы комлы терапия чаралары белән профилактикалау һәм шәхес үсеше өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән. Әлеге хезмәт 4 яшьтән алып 6 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә, кабинетның мәйданы 68,6 кв.м, балалар саны - 11.

4. **«Развивайка»** - программа урта мәктәпкәчә яшьтәге балаларның фикерләүнең логик структураларын, күренекле мәдәниятне үстерү нигезендә танып-белү сәләтен формалаштырырга, аларның үзлекләре буенча аерымлыктагы логик бурычларны хэл итәргә, үстерүче уеннар ярдәмендә балаларның танып белү һәм иҗади сәләтләрен үстерергә ярдә итә. Әлеге хезмәт 4 яшьтән алып 5 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә, кабинетның мәйданы 63,2 кв.м, балалар саны - 22.

5. **«Здоровячок»** - программа мәктәпкәчә яшьтәге баланың шәхесен һәрьяклап үстерүгә бию-уен гимнастикасы һәм стретчинг чаралары белән ярдәм итүгә юнәлтелгән. Балаларда тормыш өчен кирәкле белем һәм күнекмәләр, сәламәт яшәү рәвешенә күнегүләр формалаштыра.Әлеге хезмәт 3 яшьтән алып 5 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә, кабинетның мәйданы 75,7 кв.м, балалар саны - 22.

6. **«Тхэквондо»** -программа балаларда физик сыйфатларны үстерүгә һәм камилләштерүгә юнәлдерелгән (кызулыкка, өлгерлеккә һәм сыгылмалыкка өстенлек бирелгән). Әлеге хезмәт 4 яшьтән алып 6 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә, кабинетның мәйданы 75,7 кв.м, балалар саны - 28.

7. **«Яшь шахматчы»** - программа мәктәпкәчә яшьтәге балаларны шахмат уены принципларына өйрәтүгә, аларда бу уенга кызыксыну һәм мәхәббәт тәрбияләүгә һәм тәрбияләнүчеләрне алга таба үсеш баскычларына әзерләүгә; өлкән мәктәпкәчә яшьтәге балаларның шәхси һәм интеллектуаль үсеше өчен шартлар тудыруга, шахмат уйнарга өйрәтү аша аларның гомуми культурасын формалаштыруга юнәлтелгән. Әлеге хезмәт 5 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә, кабинетның мәйданы 63,2 кв.м, балалар саны - 30.

8. **«Грация»** - программа балаларны бию сәнгатенә җәлеп итә, мәктәпкәчә яшьтәге балаларның эстетик һәм әхлакый үсешенә ярдәм итә. Балаларга музыка тыңлый белү һәм хәрәкәттә аның күптөрлелеген һәм матурлыгын тапшыра белү күнекмәләре өйрәтә. Мәктәп баласының иҗади сәләтләрен хореография сәнгате ярдәмендә күрсәтә һәм ача. Әлеге хезмәт 5 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә, кабинетның мәйданы 102,8 кв.м, балалар саны - 27.

9. **«Яшь рәссам»** - программа мәктәпкәчә яшьтәге балаларда сәнгати-иҗади сәләтләрне үстерүгә һәм сынлы сәнгатьнең традицион булмаган формалары аша рәсем эшчәнлегенә ныклы кызыксынуга юнәлтелгән. Әлеге хезмәт 3 яшьтән алып 5 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә, кабинетның мәйданы 63,2 кв.м, балалар саны - 10.

10. **«Могҗизалы камыр»** - программа балаларда сәнгати-эстетик һәм иҗади сәләтләр формалаштыруга, шулай ук вак моториканы, пространстволы фикерләүне һәм танып белү күнекмәләрен үстерүгә юнәлтелгән. Әлеге хезмәт 3 яшьтән алып 4 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә, кабинетның мәйданы 63,2 кв.м, балалар саны - 10.

11. **«Тылсымлы куллар»** - программа вак моториканы, иҗади сәләтләрне үстерүгә һәм традицион булмаган рәсем ясау техникасын мөстәкыйль куллануга юнәлтелгән. Әлеге хезмәт 3 яшьтән алып 4 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә, кабинетның мәйданы 58,2 кв.м, балалар саны - 16.

ТР Тукай муниципаль районы
муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе –
«Миләшкәй» балалар бакчасы мөдире ________________ Е.А. Воробьева